| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.11.2021 Кадрәк № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башлыгы к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 15 ноябрендә 10 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2021 елның 15 ноябрендә 13 сәг 30 мин билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билгеләр буенча бүләргә:

-1 этап: Кадрәк авылының Ленин ур., 1- 63, Заречная урамы, 1-39 адресы буенча яшәүчеләр.

-2 этап: Кадрәк авылының Ленин ур. 63-127, Полевая 1-7, Яшьләр урамы 1-7, Сосновая урамы 1-11 адресы буенча яшәүчеләр.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадрәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кадрәк торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан

тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Кадрәк авылында лампаларга, дроссельләргә, фонарьларга хезмәт күрсәтү, ремонт ясау һәм алыштыру һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу;

2. Кадрәк авылында урамнарны кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу һәм башкарылган эш өчен түләү);

3. Кадрәк авылында Заречная урамындагы күперләрне ремонтлау (башкарылган эш өчен материалларны төзү һәм түләү);

4. Кадрәк авылында Ленин, Сосновая, Полевая, Заречная, Яшьләр урамнары өчен вак таш алу һәм ремонтлау

5. Кадрәк авылында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын штаттан тыш йөртүчегә хезмәт хакын түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

6. МТЗ-82 тракторы өчен асылма җиһазлар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Кадрәк авылы, Ленин урамы 55, авыл мәдәният йорты янындагы мәйданчык адресы буенча үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.А.Михайлов